ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2025 ел № 1020

**Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасы өчен гарантияләүче оешманы билгеләү турында**

Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә өзлексез су белән тәэмин итүне оештыру максатларында, 2011 елның 7 декабрендәге “Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында” 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 11, 12 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Таткоммунэнерго” РҖБ” АҖен Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авылы территориясендә үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасы өчен гарантияләүче оешма итеп билгеләргә.

2. Гарантияләүче оешма “Таткоммунэнерго” РҖБ” АҖнә эксплуатацияләнә торган су белән тәэмин итү челтәрләренә билгеләнгән тәртиптә кушылган абонентларны салкын су белән тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты Аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.А.Галимуллин